СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД ИННОПОЛИС»
ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район, Республика
Татарстан, 420500

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ
«ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ»
СОВЕТЫ
Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

РЕШЕНИЕ КАРАР

20.06.2025 № 42-239

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, шулай ук норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнары җыенының 01.06.2021 ел №1 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына (08.02.2022 ел № 7-42; 27.10.2023 ел № 24-136, 15.08.2024 ел № 34-192 үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән редакциядә) (алга таба - Устав) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Уставның 7 статьясының 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 43 пункт өстәргә:

«43) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

1.2. Уставның 15 статьясындагы 1 өлешенең 2 абзацында «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Уставның 16 статьясындагы 5 өлешендә «җирлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясенә» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Уставның 16 статьясындагы 12 өлешендә «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясе» сүзләрен «Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. Уставның 40 статьясына түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы таркалу Иннополис шәһәре Мэрының вәкаләтләрен туктату өчен нигез булып тормый.».

2. Иннополис шәһәре Мэрына әлеге карарны «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар аның дәүләт теркәве узганнан соң гамәлгә ашырылган Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә (http://pravo.tatarstan.ru/).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Иннополис шәһәре Мэры Д.В. Вандюков